**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**
2025 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тихоново авыл җирлегенең Тихоново авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү турында

25.10.2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге башлыгының “Менделеевск муниципаль районы
Тихоново авыл җирлегенең Тихоново авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” 2024 елның 15 октябрендәге 2 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлегенең Тихоново авылында гражданнар җыены
КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. 2025 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Тихоново авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм аларга тиңләштерелгән затлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендәге студентлардан тыш, 1000 сум күләмендә, ә күп балалы гаиләләрдән бер тапкыр бирелә торган түләүне 50%ка киметеп, 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә.

1) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Тихоново авылында асфальт һәм бетон түшәмәле юлларны төзекләндерү һәм чокырларны ремонтлау, юлларны кардан чистарту);

2) су белән тәэмин итү һәм чыгару системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (скважина өчен тирәннән су алу насосы сатып алу);

3) торак пункт территориясен төзекләндерү (үлән чабу, триммер сатып алу);

4) коймаларны ремонтлау, кору, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (авыл зиратында койма монтажлау);

5) урамнарга яктырту җайланмасы алу (урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру)

2. Әлеге карарны кабул иткәннән соң 10 көн эчендә Тихоново авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларына, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып халыкка җиткерергә һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru "Тихоново авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга

.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
ТР Менделеевск муниципаль районы
Тихоново авыл җирлеге башлыгы _____________ А.М. Карманов

(подпись) (расшифровка подписи)